РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТИМБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

09 август 2016 ел

№ 10

**«Хакимият вәкиленең оештыру-боеру, административ-хуҗалык функцияләрен башкаручы вазыйфаи затны аңа хезмәт бәйлелегендә булмаган затларга карата билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 17 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 5-ТРЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Буа муниципаль районының Тимбай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесен хакимият вәкиленең оештыру-боеру, административ-хуҗалык функцияләрен үтәүче, аңа хезмәт бәйлелегендә булмаган затларга карата вазыйфаи зат дип билгеләргә.

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Тимбай
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Вәлеев